КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 июль г.Казань № 847

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 3 июль, 535 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясенең сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган уникаль экосистеманы Иннополис шәһәрендә булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен башкару чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган уникаль экосистеманы Иннополис шәһәрендә булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 535 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 август, 745 нче; 2022 ел, 29 август, 918 нче; 2023 ел, 5 апрель, 415 нче карарлары белән кертелгән үзшәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган уникаль экосистеманы Иннополис шәһәрендә булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә

ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү белән шөгыльләнгән хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бәйле салымнарны түләү;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар белән бәйле булган элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләве, мөлкәтне карап тоту хезмәтләре, каравыл хезмәтләре, чаралар оештыру һәм үткәрү хезмәтләре, Иннополис шәһәрен яшелләндерү хезмәтләре, Иннополис шәһәренә резидентлар һәм анда яшәүчеләрне җәлеп итү хезмәтләре өчен түләү;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар белән бәйле чаралар буенча реклама кампанияләре оештыру (реклама продукциясен эшләү һәм сувенир продукциясен әзерләү);

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар белән бәйле төп чаралар сатып алу;

эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларына капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга алынган кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү өлешендә Иннополис шәһәре территориясендә бизнес оештыруга һәм алып баруга юнәлдерелгән финанс ярдәме;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү максатлары белән бәйле башка чыгымнар (банклар хезмәтләре өчен түләүне дә кертеп).»;

8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Коммерциягә карамаган оешмага, әгәр ул заявка биргән көнгә кадәр 10 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килсә, сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителә:»;

9 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта – әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган юнәлешләр буенча чыгымнар сметасын, инновация инфраструктурасын үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүнең һәм аңа карата өстәмә килешүләрнең күчермәләрен; чыгымнарны каплауга субсидия бирелгән очракта – коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнарны гамәлгә ашыруга бәйле фактта тотылган чыгымнарын раслый торган документларның күчермәләрен (коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән

ышанычнамәнең күчермәсен теркәп) тарафыннан таныкланган чыгымнар сметасы, шартнамәләр һәм аңа кушымталар, башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актлары, түләү йөкнамәләре, шулай ук (булганда) счетлар, счет-фактуралар, универсаль тапшыру документлары, керем һәм чыгым ордерлары, накладнойлар);»;

җиденче абзацта «сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә» сүзләрен «заявка бирү датасына кадәр 10 эш көненнән артмаган датага» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) (С) субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + З_4 + З_5 + З_6 + З_7,$$

монда:

$З_1$ – коммерциягә карамаган оешманың расланган штат расписаниесе нигезендә билгеләнә торган коммерциягә карамаган оешма хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$З_2$ – салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар түләү чыгымнары;

$З_3$ – элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләве, мөлкәтне карап тоту хезмәтләре, каравыл хезмәтләре, чаралар оештыру һәм үткәрү хезмәтләре, Иннополис шәһәрен яшелләндерү хезмәтләре, Иннополис шәһәренә резидентлар һәм анда яшәүчеләрне җәлеп итү хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;

$З_4$ – чаралар буенча реклама кампанияләрен оештыру чыгымнары (реклама продукциясен эшләү һәм сувенир продукция җитештерү);

$З_5$ – төп чараларны сатып алу чыгымнары;

$З_6$ – эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларына капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга алынган кредитлар буенча процентлар түләүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү өлешендә Иннополис шәһәре территориясендә бизнес оештыруга һәм алып баруга юнәлдерелгән финанс ярдәме чыгымнары;

$З_7$ – әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү максатлары белән бәйле башка чыгымнар (банклар хезмәтләре өчен түләүне дә кертеп).

Әлеге пунктта күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар гамәлдәге законнар нигезендә һәм коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган документлар, шул исәптән инновация инфраструктурасын үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүләр буенча, шулай ук бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.»;

15 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләре;»;

җиденче абзацта татар текстында «чыгымнарны» сүзе үзгәрешсез кала;

сигезенче абзацта татар текстында «чыгымнарны» сүзе үзгәрешсез кала;

22 пунктның беренче абзацында татар текстында «чыгымнарны» сүзе үзгәрешсез кала;

25 пунктның беренче абзацында татар текстында «чыгымнарны» сүзе үзгәрешсез кала.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин